МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.07.2018 г.Казань № 703

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 14 августында теркәлде, № 4833

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 елның 09 февралендәге 67 номерлы карары белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибе турында нигезләмәгә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр в.б. Р.Ф.Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2018 № 703 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгында (алга таба – Боерык):

Боерыкның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

Боерыкның 1 пунктында «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

Боерык белән расланган Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентында (алга таба – Регламент):

Регламентның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.1 һәм 1.2 пунктларда «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктның 1.4.2 пунктчасында «(http://uslugi.tatar.ru/);» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru/);» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 елның 09 февралендәге 67 номерлы карары белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү

тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы PRAVO.TATARSTAN.RU, 2018, 9 февраль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);»;

2 бүлектә:

2.1 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» һәм «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графаларында «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда) сүзләрен өстәргә;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.6 пунктның алтынчы абзацында «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

2.15 пунктның унсигезенче абзацында «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктның «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләмәнең 10, 11 п.; 63-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 11 п.; 210-ФЗ номерлы Федераль законның 21.1 ст.;

3 бүлектә:

3.4 пунктта:

3.4.1 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнарыннан бала тудырган хатын-кызның мөрәҗәгать итү датасына (вафат булу, ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү (ата-аналык хокукларында чикләнү) датасына) Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәү фактын раслаучы белешмәләр.»;

3.4.2 пунктчаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бала тудырган хатын-кызның мөрәҗәгать итү датасына (вафат булу, ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү (ата-аналык хокукларында чикләнү) датасына) Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел дәвамында даими яшәү фактын раслаучы белешмәләр, – җирле үзидарә органнарына;»;

5 бүлектә:

5.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү срогы бозылганда;»;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең) дәүләт хезмәткәренең (учреждение хезмәткәренең), җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.»;

5.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

5.8, 5.9 пунктларны тиешенчә 5.7, 5.8 пунктлар дип санарга;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Регламентка 1-5 нче кушымталарның һәм Кушымтаның (белешмәлек) нумерацияле баш исемнәрендә «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

Регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема»;

Регламентка Кушымтаның (белешмәлек) нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр.»